**ГЛАВА АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 22 нче йорт
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы

18 нче август 2026 ел № 4

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Уставының 19 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар 2026 елның 8 сентябрендә 17.00 сәгатьтә билгеләргә. Үткәрү урыны-Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Кабинеты: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22 йорт.

2. Гавами тыңлаулар күрсәтелгән көнне 17.00 сәгатьтә уздырылуын билгеләргә., гавами тыңлаулар уздыру урыны – Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22 йорт адресы буенча Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Кабинеты.

3. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануны үзгәртү мәсьәләсен исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Садретдинов Дамир Илнар улы – Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Минабетдинова Рәсимә Галимҗан кызы-Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе, эшче төркем сәркатибе;

Шәйхетдинова Ризифа Нәбиулла кызы – Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры, комиссия әгъзасы.

4. Шуны билгеләргә::

а) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләр проект буенча фикер алышуда әлеге карар белән билгеләнгән гавами тыңлауларда катнашу юлы белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясында һәм Акъяр авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә катнашалар;

б) гавами тыңлауларга әзерлек барышында гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә буенча Акъяр җирлегендә яшәүчеләрнең язма тәкъдимнәрен кабул итү, карау һәм исәпкә алу алып барыла;

в) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең чыгарылган сорау буенча язма тәкъдимнәре («гавами тыңлауларга» тамгасы белән) 2026 елның 8 сентябренә кадәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Акъяр авылы, Совет ур., 22 йорт.

Тәкъдимнәр шулай ук Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан почта аша күрсәтелгән адрес буенча җибәрелергә мөмкин.

г) Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча язма тәкъдимнәрен алдан караганда эшче төркем гавами тыңлаулар барышында каралырга тиешле мәсьәләләр арасыннан төшереп калдыралар:

- аноним тәкъдимнәр;
- әлеге карар нигезендә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләгә кагылышлы булмаган тәкъдимнәр;
- 17.00 сәгатьтән соң килгән тәкъдимнәр 2026 елның 8 сентябре.

5. Акъяр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлауларда катнашу теләге турындагы гаризалары (кызыксынган затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урынын, шәхесен таныклаучы документның төрен, сериясен һәм номерын күрсәтеп) 2026 елның 8 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә дип билгеләргә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Акъяр авылы, Советская, д.22.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы

Д.И. Садретдинов